Әлфинур Сыртланова

# Шигърият канатларында

*На крыльях поэзии*

Әлфинур Сыртланова

# «Шигърият канатларында»

## «На крыльях поэзии»

ЯҢАВЫЛ-2021



# «Шигърият канатларында»

# «На крыльях поэзии»



Янаульская городская типография,
г. Янаул, ул. Азина, 31. Тел. 8-960-383-12-34. Тираж 50 экз. Заказ 142. 2021 г.

# Кереш сүз

Мин – Сыртланова Әлфинур Сабир кызы, Башкортостанның Яңавыл районы Гөтбер авылында 1942 елның 8 мартында туганмын. Әтиле бала булып үсәргә насыйп булмаган, мин туган елның декабрендә үк әткәйдән «хәбәрсез югалды» дигән кайгылы хәбәр килә.

Бала чагым, яшьлек елларым сугыштан соңгы бик авыр чорга туры килсә дә, ачлык, ялангычлык, ятимлекне үз җилкәмдә татып, өлкәннәр белән бергәлектә авыр эшләрне башкарып үссәм дә, тормышка булган якты карашны, кешеләргә ихтирамны, яшәүгә булган мәхәббәтне югалтмадым, кешелекле, кечелекле булырга кирәклекне аңлап үстем.

Газиз әнкәем, бер туган апам ярдәме белән Яңавылның 1 санлы мәктәбенең 10 сыйныфын тәмамладым. Мәктәп яшеннән үк көндәлек алып бара идем. Кулыма таныклык алып чыккач, Стәрлетамак культура-агарту училищесына укырга кердем, әйтергә кирәк, анда алган белемне гомер буе кулланып яшәдем һәм бүген дә бу белемем матур тормыш алып барырга, кеше арасында булырга миңа зур ярдәм итә.

Шулай ук күңелемдә бик зур хыялым бар иде- шәфкать туташы булып, кешеләргә ярдәм итеп яшисем килде. Күрше Нефтекама шәһәрендә медсестралар әзерләү курсында укып, Яңаўртавыл участок больницасында 34 ел хезмәт иттем.

Тормыш иптәшем Кәзиф Таһир улы белән 47 ел бергә гомер итеп, бер кыз, бер ул тәрбияләп үстердек. Оныкларны тәрбияләшүдә дә үз өлешебезне керттек, бүген инде оныкларыбызның сабыйлары бар. Кызганычка каршы, хәләл җефетем генә иртәрәк дөнья куйды.



*Авылыбызда оештырылган «Гәүһәр» фольклор ансамбле оештырылу белән авылыбызның моңлы,уңган хатын-кызлары белән бергә мин дә актив катнашам. Һаман да мәдәнияттә булуыма сөенеп, җыр-моң белән дәртләнеп, картаерга да онытып яшим. 2015 елны зур хөрмәт күрсәтеп авылыбызның Ак инәе итеп сайладылар. 2019 елны «Хатын-кыз - милләт анасы» дигән район күләмендә беренче медаль һәм диплом бүләкләнүем дә минем өчен зур сөенеч һәм горурлык булып тора.*

*50 яшемдә беренче тапкыр каләм тибрәтә башлаган идем, «Миләшем» дигән шигыремне яздым. Соңрак башкалары туды. 2016 елны беренче шигырь җыентыгым басылды. Минем күңелемдә туган шигырьләрне «Яңавыл таңнары» газетасының тугры укучылары да күрә алды. Якыннарымның туган көннәренә, төрле бәйрәмнәргә атап та язылган шигъри күчтәнәчләрем бар. Якташыбыз Гөлнара Зыязова өч шигыремә көй язды.*

*Үземнең уйларымны, теләкләремне чагылдырган иҗат җимешләрем белән сезнең белән дә уртаклашам.*

# *Бераз үзем турында*

Язның беренче көнендә
Мин дөньяга килгәнмен.
Яз кояшы кебек балкып,
Һәрчак елмаеп яшимен.

Кайберәүләр әйтәләр:
«Бигрәк дәртлесең»,– диләр, –
«Яшь чагыңдагы кебек
Йөгереп йөрисең», – диләр.

Булмаганга көймичә,
Булганга шөкер кылып,
Дәртләнеп яшимен әле,
Шатлык, бәхеткә уралып.

Бик игътибар да бирмим
Начар, гайбәт сүзләргә.
Горур басып китеп барам
Астан караган күзләргә.



Куанып яши белик әле
Тормышның ямен тоеп.
Шатлык барда шатланып
Моңланганда моңаеп.

Гомер көзенә җитсәк тә
Яшик әле дәртләнеп.
Картайгач әйтерләр әле
«Дәрте – дәрманы бар» дип.

Дәртле кеше көчле ул
Яши авырлыкларны җиңеп.
Дәрт ул яшәргә көч бирә
Алга, киләчәккә әтәреп.

Моңсыз булып тоелса да
(Дәртле кеше – моңлы ул).
Дәртле моңнарга уралып
Үтсен һәрчак тормыш юлы.

# Ана йөрәге

Авылымның яме, нуры – эниләрдә.
Якты йөзле, тәмле сүзегез.
Инде купме яшькә җиттек диеп
Ямансулап, моңаеп йөрмәгез.

Нинди авыр хәлдә калсагыз да
Бөркелә һәрчак сездәге җылылык.
Мәрхәмәтлелек, наз, изгелек
Барлык кешеләргә дә җитәрлек.

Үзләрен бик бәхетле саныйлар
Бала-чагасы булган апалар.
Икеләтә бәхетле, балалары
Һәрчак уз янында булганнар.

Алыштырмый аларны бернәрсә
Балалар – Ходайның бүләге.
Озын гомер, шатлык, бәхет теләп
Һәрчак тибә ана йөрәге.

Баланың әле бит «чага»сы бар,
Белми Ана аның кайчан чагасын.
Мәрхәмәтле, изге ана йөрәге
Һәрчак кичерә газиз баласын.

Назлы гөлләрдән наз алып
Сайрар кошлардан моң алып.
Яшәгез җирдә бәхетле булып
Һәрчак таң нурыдай балкып.

Ходай тәгаләдән бирелгән ул
Балаларга булган мәхәббәт.
Тәүфыйклы, игелекле булсыннар иде
Әти-әниләргә, илгә нык терәк!



# Мәрхәмәтле әнием

Күптән доньядан китсәң дә
Гел төшемә керәсең.
Әнкәй, сине хәтерләтеп,
Чәчәк аткан миләшең.

Синең янда булган икән
Иң бәхетле көннәрем.
Син доньяны куйгач кына
Ялгыз калгач – аңладым.

Алма чәчәге хәтерләтә
Синең ак күлмәгеңне.
Бала чакта бергә булган
Иң кадерле көннәрне.

Син күрсәткән изгелекне
Ничек, әнием, бәхиллим?
Син өйрәткән догаларны
Хәзер үзеңә багышлыйм.

Бик авыр минутларда
Һаман сиңа эндәшәм.
Синең хәер-фатихаңны
Мин шул чагында тоям.

Сугыштан соң авыр еллар –
Калдың син ятим, ялгызың.
Бар эш синең иңеңдә иде
Булдың ир, хатын да үзең.

Авырлыкларга бирешеп
Бөгелеп-сыгылып төшмәдең,
Үзең карап үстердең безне,
Чит-ят кулына бирмәдең
Минем газиз әнкәем.

***

Иңнәремдә фәрештәләр
Бәла-казадан саклыйлар.
Фәрештәдәй балаларым
Өметләремне аклыйлар.

Йөрәк ярасына түзәлмичә
Сызланганда дәва булырга
Ярый әле туганнарым бар
Тугры булып сиңа калырга.

Янымда якын дус-ишләрем
Хәлемне алар аңлыйлар.
Күземдә яшь, күңелемдә сагыш
Моңаерга ирек бирмиләр.

Хәстәрлекле минем күршеләр,
Кешелекле, олы җанлылар,
Мәшәкатьле бу тормышта
Миңа да вакыт табалар,
Хәлләремне белеп торалар.

*2017 ел.*



# Кайгылы сагыш

Бергә яңа елны көтеп ала идек
Тик шатлык-бәхетләргә куанып.
Быел килде бураннары белән
Сагышлы таң, зарларга уралып.

Бетми икән ул сагышлар ,моң
Инде купме айлар үтсә дә
Йөрәгемдә әрни һаман яра
Кышлар үтеп язлар җитсә дә.

Өметләнеп көттем язларны
Кайтарыр диеп үткән көннәрне.
Бәлки кар сулары басар дип,
Утсыз дөрләп янган йөрәгемне.

Өмет иттем җәйнең бизәкләре
Төзәтер диеп йөрәк ярамны.
Тик синең белән булган икән
Гомеремнең бәхетле көннәре.

Шушы сагышларга түзәлмичә
Йөрәгемә өстәлде тагын бер яра.
Син хәзер ялгызың инде, диеп
Моңсуланып сайрый кошлар да.

Авырсаң да бер дә зарланмадың,
Кайгырмадың һич тә юк-барга.
Гомеремнең иң матур мизгелләре
Булган икән, бары син барда.

Син генә кичердең ялгышларымны
Яшеренгән тирәндәге хисләремне.
Мең рәхмәтлемен янымда булганың өчен
Синнән башка янымда юк якын кешем.

Син булмагач ямансулап калды урам,
Синсез туган йортың калды моңаеп.
Үзең утырткан шомырт чәчәк атып,
Юксынып коя инде иртә чәчәген.

Яңгыр ява поскаклап һәркөн саен,
Кояш сирәк карый болыт астыннан.
Мәчеттә хәзер намазга башкалар
Инде синең урыныңа бастылар.

Юк, гомерне кире кайтарып булмый,
Сагынсам да кайтмассың инде.
Үземнең моң-сагышларым белән
Гомерем көзендә каламын инде.



# Өмет

Көннәр төннәргә бәйләнгән
Сизелми дә гомер үтә.
Гомер көзенә җитсәм дә
Күңел язларын көтә.

Яз артыннан җәйләр килер
Ак чәчәкләргә күмелеп
Яшисе килә җирдә тагын
Мул чәчәкләргә төренеп.

Җәй артыннан көзләр килер,
Илгә мул уңыш алып.
Тагын да яшисе килә алда
Җылы, назлы язны көтеп.

Гомер көзенә җиткәнне
Һич тә аңламый бу йөрәк.
Алда туачак язны күрергә
Омтылып яшәргә кирәк.

## Әтәч елы 2017 ел

Үзе бик җитез, үзе көчле
Үзе матур, бизәкле.
Кызу канлы, тиктормас
Килә быел әтәч елы.

Авылымның тормыш яме, җыры
Әтәчнең тавышында.
Ишетелә ул еракларда,
Кырларда, урманнарда.

Горур атлап, ныклы басып
Җырлап, биеп кенә йөри.
Әгәр дә чит ятлар килсә
Үз биләмәсенә кертми.

Көне буе сакта тора
Бер күккә карый, бер җиргә
Әгәр дә куркыныч туса
Тиз генә җыя «убежищега».

«Мин сезне яклармын», – ди
Рәнҗетсә сезне берәү.
Яклармын да , саклармын да
Үзегез дә булыгыз ди, уяу.



Сез тук булсагыз, мин дә тук, ди,
Ач калмагыз берегез дә.
Хуҗабикә ачуланмасын
Йомырка салыгыз, ди, көн дә.

Йомырка салып утырыгыз
Хуҗабикә, ди, сөенсен.
Мин дә канәгать булырмын
Чебиләр күбрәк чыксын.

Җиләк-гөмбә җыйганда
Урманга кереп адашсак,
Табарсың син авылыңны
Әтәчләр тавышыннан.

Әтәчнең тавышы уята
Авылны таңнар атканда.
Тыныч та,уяу да булыр авылым
Сакта әтәчләр торганда.

# Ялгызлык

Ялгыз калдым юл чатында
Белмим кай якка барырга
Әллә уңга, әллә суңга
Әллә артка карап алырга...

Ялгыз калдым юл чатында
Карыйм үткәннәргә әйләнеп.
Әгәр мөмкин булса үткәнгә
Кайтыр идем тик сине алып.

Икәү үткән тормыш юлында
Эзләп йоримен синең эзне.
Күз алдыма китереп, ялгыз
Синсез үтәр, калган гомерне.

Үтелмәгән юллар озын диеп,
Бергә үтәсе көннәр күп диеп,
Өмет белән якты киләчәккә
Яши идек әле пар канат булып.



Синең белән бергә булганда
Онытыла сагышларым.
Шушылай күп булган икән
Танышларың, дус-ишләрең.

Ничә еллар инде шулай
Онытырыга сине тырышам.
Хәзер инде синең белән тик
Төшләремдә генә күрешәм.

Нигәдер шулай – аңламыйм
Көнем төнем белән бутала.
Сине уйлап уза минем гомер
Йөрәгемне сагыш, моң баса.

Ике гомер яшәү мөмкин түгел
Килми артка таба карыйсым.
Үткәннәрдән тик яхшылыклар
Мәңгегә хәтеремдә калсын.

# «Гәүһәр»ләргә:
# Сезнең белән бәхетлемен

Үзе бәхет, олы шатлык бит ул
Сезнең белән бергә булуым.
Сездән дәрт, илһам алып
Үземне яшь итеп тоюым.

Үзе бәхет, олы шатлык бит ул
Сезне кабат күрүе.
Сезне күреп, хыялланып
Яшьлегемә кайтып килүе.

Үзе бәхет, олы шатлык бит ул
Дус-ишләрнең шулай күп булуы.
Эчең тулы сагыш булса да
Үзеңне бәхетле итеп тоюы.

Үзе шатлык, олы бәхет бит ул
Гомер итүе туган җиреңдә.
Сезнең белән яңадан яшәрәмен
Инде олыгайган көнемдә.

Һәр иртә таңны каршылап,
Шатлык-бәхетләр белән уянып.
Яшик әле шулай һәрчак бергә
Артаулны җыр-моңга күмеп.



# Без әле балкыйбыз

Аллага шөкер, ничә еллар
Без бергәбез һаман бүген дә.
Әле бит  без балкыйбыз
Артаул сәхнәсе түрендә.

Бездән башка Артаул сәхнәсе
Булмас иде шундый ямьле, нурлы
Яңгырамас иде гармун телләре
Халкымның дәртле көйләре.

Яшьлек үтеп, олыгайсам да
Килми бит сездән китәсем.
Моңың бетеп, дәртең сүнсә
Хушлашырга! Нихәл итәсең.

# Карт әтием

Балаларым булгач белдем
Әткәйнең кем булганын.
Әткәй сугышка киткәндә
Яңа туып кына калганмын.

Карт әтиемнең олы улы
Минем әткәем булган.
Дошманны җиңеп кайт,диеп,
Азан әйтеп озаткан.

Әткәемнең дәүрт баласы
Бер-бер артлы дөнья куйган.
Безне ике кызын кочаклап
Исән кайтырга сүз биргән.

Карт әтинең чабатасы
Кыш көне җиңел, йомшак иде.
Ә язларын күтәрмә аша
Бозлы су үтеп керә иде.



«Хәбәрсез югалды» диеп
Кайгылы кәгазь килгән.
Карт әтием бу кайгыдан
Вакытсыз дөнья куйган.

Бер тапкыр күрмәсәк тә,
Төшләребезгә кермәсә дә,
Көттек барыбер әткәйнең
Инде кайтмасын белсәк тә.

Карт әтиемне уйласам
Күзләремә яшь тула.
Әткәй бит карт әтиемнең
Иң кадерле, газиз улы була.

Сугыш газабын кичерде
Күпме җирдә газиз аналар.
Ятимлектә үсмәсеннәр
Бездән соң башка балалар.

# Ялгыз нарат

Тау өстендә ничә еллар
Үсеп утыра ялгыз нарат.
Тирә-ягы яшел болынлык
Аста чишмә ага чылтырап.

Горур тора төсен саклап
Ул ничә яшькә җитсә дә.
Куркытмый көчле җиле дә
Бирешми салкын кышка да.

Җәйләр җиткәч яшел болында
Үсәләр каен-җир җиләкләр.
Кып-кызыл җиләкләр белән
Тулып кайталар чиләкләр.

Чәчәктән чәчәккә үрелеп,
Кояш нурына күмелеп,
Уйнап очалар күбәләкләр,
Ямьле җәйләргә сөенеп.

Бөрлегәннәр уратып алган
Елганың тирә-ягын.
Табигатькә ямь өстәп
Сандугач сыза моңнарын.



# Дәү әни

Кош баласын очыргандай,
Тараткач балаларын,
Хәстәрлекле дәү әниләр
Тәрбияли оныкларын.

Үзен бәхетле тоядыр
Оныклары булганнар.
Тормышның ямен, тәмен
Алар бит кабат тоялар.

Иң тәмле ризыклары белән
Оныкларыңны сыйлысың.
Берүк күз тимәсен, диеп
Өшкереп, дога укыйсың.

Колачларыңны җәеп,
Җил-давыллардан саклап
Үстерәсең оныкларыңны
Кочагыңда сөеп, иркәләп.

Сагынып кайталар оныклар
Дәү әнинең тәмле ашларын.
Сокланып күреп туймыйлар
Аның җылы, назлы карашын.

Ярый әле, кояш кебек балкып,
Йөрәк җылысын тигез итеп,
Яшиләр җирдә дәү әниләр
Бар оныкларына өләшеп.

## Парлы гомер

Кошлар да оя коралар парлашып
Чишмә дә ага үзенә юл табып.
Язмышлар безне очраштырды
Гомер сүтәргә икәү парлашып.

Бергәләшеп без дә оя кордык
Бер-бер артлы туды балалар.
Алар ата-аналы булсын дип
Үтеп киткән шулай гомерләр.

Алда көтте бик күп сынаулар
Барыр юлыбыз булды бормалы.
Язмышларны булмый үзгәртеп
Кеше күрә үзенә язганны.

Бөгелсәк тә, сыгылып төшмәдек.
Арабыздан үткән ачы җилләрдә.
Алтын көзебезгә килеп җиттек
Гомер йомгакларын сүтәргә.

Насыйп булды безгә парлы гомер
Әйдә, Аллага шокер, бергәбез.
Балаларыбыз изгелегендә
Тормышыбызга куанып яшибез.



# *Каерылды канатым*

Кисәк кенә көтмәгәндә
Каерылды ныклы уң канатым.
Яраларына түзәр өчен
Ходайдан сабырлык сорыймын.

Кинәт каерылды да сынып,
Килеп төште салкын җиргә.
Салкыны өшетә ярамны
Көч бир, Ходаем, түзәргә.

Эй, язмыш, нигә көтмәгәндә
Ныклы канатымны каердың?
Йөрәгемә бетмәс яра ясап
Гомерлек юлдашымнан аердың?

Аерылды хәзер гомерем икегә
Аерылгандай язлар көзләргә.
Икебезнең бәхетле көннәргә
Синсез үтәр моңсу төннәргә.

Канатларым сынмасын, диеп
Гомеремдә куркып, теләп яшәдем.
Күрмим хәзер доньяның ямен
Тоймыйм азыкның тәмен.

Әле яңа гына башлаган кебек
Бергә парлап гомер итәргә.
Тормыш ямьле, түгәрәк иде
Икәү парлап канат какканда.

Икәү бергә башлаган идек бит
Гомер йомгакларын сүтәргә.
Насыйп булмады бергә бетәргә,
Калды инде үземә генә.

Ташлап киттең, ялгыз иттең
Бигрәк авыр синнән аерылу.
Җиңел булмас инде синсез
Ялгыз гына канат кагыну.

Үз гомерләренә серләшеп
Парлылар яшиләр бит гел бергә.
Шушы парлыларның гомерен
Ходаем ник җәлләдең безгә?



## 2021 елның җәе

Быелгы җәй бигрәк эссе булды
Бар табигать суга сусады.
Үләннәр дә иртә корыдылар
Агач яфраклары саргайды.

Чишмәләр дә тиз саекты
Иртә тынды сайрар кошлары.
Табигатьнең бар җан ияләре
Күләгәгә сыенып хәл алды.

Эссе җилләр иркәләп исте
Иген кырлары чайкалды.
Башак җиткәнен белдереп
Сабан тургайлары сайрады.

Табигатьнең олы бүләге
Игеннәр бирде мул уңыш.
Тәгәрәп үстеләр җимешләр
Тик эшкәртеп кенә житеш.

Сыгылып торган өстәлләр,
Табыннар булсын ямьле
Шаулап үскән игеннәрдән
Икмәкләре булсын тәмле.

# «Гәүһәр» ансамблем

Мәшәкатьләр күп доньяда
Онытып торыйк беразга.
Хуш киләсез, ял итәргә
«Гәүһәр» чыгышын карарга.

Авылыма моңнар таратты
Җәлеп итеп күпләрне.
Көне-төне балкып яналар
Мәдәният утлары.

Күңелегезгә хуш килсен
«Гәүһәр»нең һәр чыгышы.
Безнең араны бәйләсен
Җылылык, дуслык хисе.

Алкыш белән каршылагыз
Безнең һәрбер чыгышны.
Безгә тагын дәрт өстәр
Күтәрер ул күңелне.

Безнең «Гәүһәр»гә йөриләр
Сәнгатьне сөючеләр.
Тормышка наз, ямь өстәп
Җыр-моңга тәрүчеләр.



Ансамбльгә йөриләр
Авылыбыз уңганнары.
Җитдиләре, булганнары
Җыр-моңга гашыйклары.

Олысы да, кечесе дә йөри
Ихластан сәхнәне яратып.
Уңышлы чыгыш ясыйлар
Артаул данын таратып.

«Гәүһәр» баянисталары да
Сузалар авыл көйләрен.
Йокыларыннан уятып
Тибрәтеп йөрәк кылларын.

# Туган көн

Җырлап акты кар сулары,
Кошлар кайтты оя корырга.
Агачлар бөреләренсузды
Туган көнең белән котларга.

Бакчадагы сандугачлар
Синең хакта сайрыйлар.
Туган көнең белән котларга
Матур көйләр сайлыйлар.

Туган көнең белән котлап
Ап-ак чәчәк атты сиреньнәр.
Табигатьнең гүзәллеген алып
Алгансың үзең дә сиреньнән.

Бүген нинди матур, аяз көн
Шундый якты, нурлы иртәләр.
Туган көнең белән котлап
Сине назлап җилләр исәләр.

Язлар бик ямьле булса да
Җитми ул туган көнгә.
Язлардай әйләнеп килсен
Туган көнең һәр елда.

Бик тиз үтсә дә туган көн
Килер ул һәр ел әйләнеп.
Күтеп ал син бу мизгелне
Шатлык, бәхеткә бәйләнеп.

Туган көнең белән котлап
Чәчәк аткан тәрәз гөлләрем.
Гүзәл чәчәкләргә күмелеп
Үтсен алда гомер юлларың.



# Гомер юлы

Беркемнең дә тормышы
Ак юлдан гына бармый.
Була аның карасы да,
Вакыт җиткәч дәвалый.

Авырлыкны кичермичә
Үтеп булмый карасын.
Ерып чыгар өчен аны
Ходаем күрсәтә юлын.

Үткәрмик булган гомерне
Уфтанып, зарланып. Яшик
Гомернең кадерен белеп.
Язмышыбызга буйсынып.

Авырлыкны җиңәр өчен
Ярдәм кирәк дус-иштән.
Кемдер килеп кулын бирсә,
Арчаланырсың сагыштан.

# Яңавыл якты юлга итә ул

Яңавыл, синдә үтте минем
Бәхетле үсмер, яшь чагым.
Олы юлга чыгардылар
Кадерле укытучыларым.

Мәктәпкә озатып йөрделәр
Юл буендагы ак каеннар.
«Яңавылга лаеклы үс» дип
Теләк теләп калдылар.

Ямансулап, сине ташлап
Язмыш кушкан юл белән,
Күпме читтә яшәсәм дә
Кабул итәрсең, беләм.

Кошлар очып кайткан кебек
Сиңа әйләнеп кайттым.
Кайттым, газиз туган ягым,
Синнән якын төбәк тапмадым.

Синдә ныклы белем алдым
Якты киләчәккә атладым.
Синнән башка яши алмамын,
Синдә калды яшьлек елларым.

Бүген дә киләм әле сиңа
Мәктәп еларымны сагынып.
Яңавыл көннән-көн матурлана,
Яшимен синең белән горурланып.

Сине тагын назга күмеп
Чәчәк аткан бакча гөлләрең.
Хәтта авылымны яктырта
Балкып янган якты утларың.

# *Ходаема шөкермен*

Һәр таңда күземне ачам
«Ходайга шөкер» диеп.
Бүген дә куанабыз икән
Якты доньяны күреп.

Тәрәзәдән тышка карыйм
Нинди матур таң ата.
Таң нурлары күңелләрдә
Яшәү дәрте уятса.

Бик авыр минутлар була
Яшәи алмыйсың кебек.
Иртән тагын уянамын
Нурлы таңнарны күреп.

Һәр кич саен «Бисмилла» диеп
Белгәннәрн укыймын.
Балаларга, туганнарга,
Дусларга, күршеләргә
Имин донья телимен.

# Илһам юлы

Без яшибез бу доньяда кунак булып
Бу дөньяның газабын, рәхәтен тоеп, белеп.
Белми кылган гонаһларыбызның
Ходаемнан ярлыкауын сорыйк.

«Әссәләмүгаләйкем»диеп сәләм бирик
Бер-беребезне яшик хөрмәтләп.
Гайбәт,гыйбрәттән ерак торыйк
Хәрәм, хәмердән арчаланыйк.

«Лә иләһә илләһү»не еш әйтик
Ул бит шәһадәтнең бер өлеше.
Һәр эшне башлыйк «Бисмилла» диеп
Илаһыбыз булыр безгә мәрхәмәтле.

Ходаем кушкан юл белән барсак,
Тәүбә кылып иман юлына бассак,
Кылган эшләребез булыр изгелекле,
Ярлыкар ходаем гонаһларыбызны.



# Өмет

Өмет итеп көтәмен әле
Болытларның таралуын.
Өметемне югалтмыйм
Төн артыннан көн килүен.

Гомер юлында күп булды
Уйламый кылган күп эшләр.
Йөрәккә үтеп керделәр
Гафу итәлмәслек сүзләр.

Күп булды гомер иткәндә
Уйламыйча әйткән сүзләр.
Ходайдан сабырлык сорап
Тешне кысып түзгән көннәр.

Яшәр өчен көч, дәрт биргән
Күңел эретерлек сүз калды.
Вакытлыча авырлыкны
Сабырлыкта җиңеп булды.

Гафу итсәң дә онытылмый.
Ялгыш кылынган гамәлләр.
Бик тиз генә төзәлмәс инде
Йөрәктә калган, тирән эзләр.

# Картлык шатлык түгел

Картлык шатлык түгел дә ул.
Узып булмый Ходай биргәннән.
Картлыкның да үз яме бар бит.
Нәкъ  үзенә генә хас бизәктән.

Пөхтә, матур киенәсе килә
Үзеңнең яшеңне хөрмәтләп.
Безнең өчен бирелгән вакытны
Һәр минутын кадерләп.

Яшьлек бит ул гомер бизәге
Бәхетне тоя күпләр картлыкта.
Мәшәкатьләрдән арчаланып,
Гомере үтә, бәхет-шатлыкта.

Еллар саны арта барса да
Куанып яшик һәр туар көнгә.
Картаямын диеп борчылмый.
Яшәү дәртен сүндерми күңелдә.

Картаямын дип, син зарланма.
Картаю ул гомер йомгагы.
Шул йомгакны сүтәр өчен
Ходай гомер бирер әле тагын.

Гомер йомгакларын сүткәндә
Парың булсын һәрчак яныңда.
Ходаемның мәрхәмәтендә
Үтсен картлык кадер-хөрмәттә.

Ходай безне шулай бар иткән
Гомеребез аның кулында.
Кәнәгатьле булып яшик әле
Рәхмәтле булып барысына.

Шау-гөр килеп яшәп калыйк
Бүгенге көн кабатланмас.
Кадерлик гомерне исән чакта
Доньяга кабат туып булмас.

Гомерләр узган саен һәркем
Якынаеп бара картлыкка.
Балаларның изгелегендә,
Картлык үтсен иде бәхеттә.

# Бәхет нәрсә ул?

Бәхет диган төшенчәгә
Бик күп гамәлләр сыя.
Һәркемнең дә үз карашы
Кемнәр ничек бәхетне тоя.

Кемнәр өчен бәхет-байлык.
Гомер буена байлык җыя.
Байлык өчен калтыранып,
Яши бәхет хисен тоймыйча.

Бәхет бит ул янәшәдә генә,
Яшә донья матурлыгын күреп.
Туганнарың, дусларың белән
Яхшы мөнәсәбәттә булып.

Доньяда яшәве үзе бит бәхет,
Бәхет – сәламәт, таза булуда.
Туганнарың исән-сау булып
Балаларың булуы яныңда.

Кыенлыктан соң бәхет килә
Сабыр итеп түзә белсәң.
Менә шунда бәхет булыр
Авыр чакта дуска булышсаң.
Рәхмәт сүзләрен ишетсәң,

Һәр мизгелдән яшә ямь табып
Бер-береңне хөрмәт итеп,
Булганына шөкер итеп
Күңел тынычлыгын тоеп.

Бәхет бит ул сәламәт булып
Иркен итеп сулыш алуда.
Күзең күреп, кояш нурының
Җылылыгын тоеп яшәүдә.



Картаямын дип, син зарланма.
Картаю ул гомер йомгагы.
Шул йомгакны сүтәр өчен
Ходай гомер бирер әле тагын.

Гомер йомгакларын сүткәндә
Парың булсын һәрчак яныңда.
Ходаемның мәрхәмәтендә
Үтсен картлык кадер-хөрмәттә.

Ходай безне шулай бар иткән
Гомеребез аның кулында.
Кәнәгатьле булып яшик әле
Рәхмәтле булып барысына.

Шау-гөр килеп яшәп калыйк
Бүгенге көн кабатланмас.
Кадерлик гомерне исән чакта
Доньяга кабат туып булмас.

Гомерләр узган саен һәркем
Якынаеп бара картлыкка.
Балаларның изгелегендә,
Картлык үтсен иде бәхеттә.

# *Бәхет нәрсә ул?*

Бәхет дигән төшенчәгә
Бик күп гамәлләр сыя.
Һәркемнең дә үз карашы
Кемнәр ничек бәхетне тоя.

Кемнәр өчен бәхет-байлык.
Гомер буена байлык җыя.
Байлык өчен калтыранып,
Яши бәхет хисен тоймыйча.

Бәхет бит ул янәшәдә генә,
Яшә доньякатурлыгын күреп.
Туганнарың, дусларың белән
Яхшы мөнәсәбәттә булып.

Доньяда яшәве үзе бит бәхет,
Бәхет – сәламәт, таза булуда.
Туганнарың исән-сау булып
Балаларың булуы янында.

Кыенлыктан соң бәхет килә
Сабыр итеп түзә белсәң.
Менә шунда бәхет булыр
Авыр чакта дуска булышсаң.
Рәхмәт сүзләрен ишетсәң,

Һәр мизгелдән яшә ямь табып
Бер-береңне хөрмәт итеп,
Булганына шөкер итеп
Күңел тынычлыгын тоеп.

Бәхет бит ул сәламәт булып
Иркен итеп сулыш алуда.
Күзең күреп, кояш нурының
Җылылыгын тоеп яшәүдә.



# Яз килә

Мин бит язның беренче
Март аенда туганмын.
Шуңа күрә һәр язны
Сагынып көтеп аламын.

Ачы җиле, кар бураны
Тик гомере озын түгел.
Моңлы сандугачы белән
Матур җылы яз килер.

Сагындыра. Язга чыккач
Котырса да салкын бураны.
Ак кары, саф һавасы
Кызылтүше, матур кошы.

Шөкер, Аллам! Җиттек язга
Кыш фасылы китеп бара.
Тазалыкта, тынычлыкта
Яшәргә насыйп ит алда.

Ялда үткән гомеремә
Бер ел өстәлде тагын.
Шатланабыз, сизмибез шул
Гомернең кыскарганын.

Сатып алып булмый торган
Алтынга тиңдәш вакытны,
Бүгенге көнне уйлап яшик
Бүген – иртәгәнең нигезе.

Без бит бу җирдә кунак кына
Һәр мизгелнең кадерен белеп
Яшик, юк бар өчен борчылмыйк,
Донья шул кадәр матур дип.

* * *

Бәхет бит ул әйбер түгел
Сатып алып булмый акчага
Бәхет бит ул аяк астында
Тик кирәк аны күрә белергә.

Иң бәхетле чак – балачак
Урта яштә аны таймыйсың.
Мәшәкатьләдән арчалангач
Өлкән яштә кебек тоясың.

* * *

«Җылы сүз – җан азыгы», диләр
Бу бит мөнәсәбәтне төзәтү.
Бер-береңә әйткән йомшак сүзләр
Таш бәгырьлелекне эретү.

Йөрәктәге бозны да эретә
Саф күңелдән чыккан яхшы сүз.
Кыйммәтле бүләктән мөһим
Мактап әйтелгән, матур сүз.

Комплимент әйтү кешегә
Бит сәнгатьнең бер өлеше.
Һәр күңелгә хуш килердәй
Таба белергә кирәк сүзне.



# Яңа ел

Көтеп алган карлар ява
Җемелдәшеп җирдә ята.
Яңа елны алып килергә
Кыш бабайга юл сала.

Карлар ява, ап-ак карлар
Бу нинди матур могҗиза!
Матурланды, донья сырланды
Яшәү дәрте артты күңелдә.

Салкын кышы, бураны да
Җылы булып миңа тоела.
Кискен, әче җилләре дә
Рәхәт бирә минем күңелгә.

Каршылыйк әле Яңа елны
Яхшы уй, изге теләктә.
Күп милләтле халкым яшәр
Татулыкта, дуслыкта.

Иске елда калсын иде
Югалтулар, борчулар.
Әрнеп сыкранган күңелгә
Тулсын иде шатлыклар.

Саф мәхәббәт, чын сөюне
Алып килсен ак карлар.
Яңа елда кавышсыннар
Адашып калган ярлар.

Ходаем насыйп итсен
Яңа елда сәләмәт булып,
Ап-ак кардай ак бәхеткә
Яшәргә язсын төренеп.

***

Кайттым әле туган авылыма
Яшьлегемә, бала чагыма
Әнкәемнең ак сирене
Шау чәчәк аткан чагында.

Сирень чәчкәсендә тоям
Әнкәемнең сөю, назларын.
Саклый кебек ап-ак чәчкә
Әнкәемнең киңәшләрен.

Ак сиреньнең ак чәчәге
Тирә-якка хуш ис тарата.
Сүнеп барган йөрәгемдә
Кабат яшәү хисе уята.

Киңәш бирче ап-ак чәчкә ,
Ничек яшәмәскә моңаеп?
Үтә гомер көзе ялгызлыкта
Сагышларыма уралып.



Ак сиреннең ак чәчәге
Иртә караймасын, шиңмәсен.
Әнкәйләрнең истәлеге
Берүк онытылмасын, сүнмәсен.

Ап-ак сиреньгә кызыгып
Өзмәгез берүк чәчәген
Саклый ул бит миңа булган
Әнкәйнең хөер-догасын.

Ак сиреньнең ак чәчәге
Ялгызларга була сердәш.
Сагышларымны басарга
Миңа да бирер бер киңәш.

Әнкәемнең үстергән сирене
Һаман да матур, һаман да яшь әле.
Әнкәемнең кулларыдай
Бик күп авыруга шифалы.

## Оныгым Ильясның туган көне

Доньяга килдең Ходай биргән
Җәйнең матур, изге көнендә.
Беренче авазыңны салгач
Әйтерсең бергә донья сөенә.

Беренче авазыңны ишетеп
Тынып калды кебек бар донья.
Безнең белән бергә куанып
Бар табигать нурга күмелә.

Пәйгамбәрләр исемен сайлап
«Ильяс» дип куштык исемне.
Булсын дип изге табигатьле,
Бәхетле, тәүфыйклы, гомерле.

Акыллы, зирәк булып үс син
Терәк булып әтиеңә, әниеңә
Ыруыбызның дәвамы бит син
Нәсел җебе калсын синнән дә.

*8 август 2008 ел.*



* * *

Кул ярасы тиз төзәлсә дә
Тиз генә төзәлми йөрәк ярасы
Гомерендә вакыт аша сыналып
Ниләр ишетми адәм баласы.

Әгәр ярамаган сүз әйтсәң
Калыр йөрәктә мәңге җәрәхәт.
Яхшы сүз җан азыгы , диләр
Мәрхәмәтле сүздә бит бәрәкәт.

Телне тыя белү – үзе савап,
Яшик рәнҗетми туганнарны.
Кирәкмәгән сүзләр сөйләп,
Күршеләрне, якын дусларны.

Сезнең белән бер күрешү
Үзе бит ул бәхетле мизгел.
Күрешеп тә, сөйләшеп тә
Һич туймас кебек күңел.

Дуслар, туганнар җыелгач
Һич тынмый бит ул күңел.
Моң сөюче дуслар өчен
Җырламыйча мөмкин түгел.

***

Яшьлегеңдә уйламыйча
Күп хаталар эшләдең.
Ялган мәхәббәтне син
Башкалардан эзләдең.

Җил дә үтеп кермәс дип
Ышандым икебезнең арага.
Әллә ялгыш, әллә язмыш-
Ятлар керде арага.

Нидән икебезнең араларда
Һәрвакыт берәү булды.
Мәңгегә дә төзәлмәслек
Йөрәккә яра салды.

Гафу итсәм дә онытылмас
Йөрәктәге ачы яралар.
Бергә тату яшәсәк тә
Ерагайды безнең аралар.

Бәлки аркынлап төзәлер
Йөрәктәге әче яралар.
Тиз генә якынаймас инде,
Ерагайды безнең аралар.



***

Безнең төбәктә урнашкан
Башкортостанның тоньяк капкасы.
Тирә-ягы гаҗәеп матур урман
Мул җир асты байлыклары.

Утка кергән, сулар кичкән
Төшмәгән ул коллыкка.
Бөгелсә дә сыгылмаган,
Омтылган тик бәйсезлеккә.

Туган респаубликамның һәрчак
Яшәү көче бердәмлектә.
Күп милләтле халкым яши минем
Тынычлыкта, татулыкта.

Буын-буыннарга күчкән ул
Башкорт халкымның теле.
Илемне данлап, зурлап җырлый
Аның моңлы, дәртле курае.

Якты кояш нуры кебек
Яктырытып гомер юлым
Яңгырый ул бөтен илдә
Мәңге сүнмәс кураем.

Һәрчак хезмәттә, көрәштә
Уңган, җиңгән батыр халкым.
Әле дә җиңүләр яуйлыйсың
Гүзәл Башкортостаным.

Рәхәт бит туган җирдә яшәү
Уз туган телеңдә сөйләшү.
Саф һавасын сулап, ямен тоеп
Үз авылымда гомер кичерү.

Берни дә куркыталмас
Кыю, батыр ул минем халкым.
Әйдә алга, юллар ачык,
Туган Башкортостаным.

Авырлыктан курыкмыйча
Телне яклап, динне саклап,
Горурланып алга атлый
Хезмәтә, көрәштә җиңү яулап.

***

Туган телем – мөхәммәт өммәтендә
туган газиз әңкәйнең теле
Сугышта мәңгелеккә башын салган –
газиз әткәйнең теле.
Кәккүк тавышын чыгарган – картәтиемнең теле.
Бишек җырында йоклаткан – дәү әниемнең теле.



***

Хатын-кыз өчен матур бәйрәм
Бирелгән елга бер көн генә.
Әниләр изгелеге турында
Күпме җырлар туалар җирдә.

Хатын-кызга бүләк өчен
Чәчәк аталар җирдә гөлләр.
Гөлләр кебек матурлыкны
Җиһанга өләшә шуңа алар.

Иң бәхетле бала-чагым
Һаман әле төшкә керә –
Урам тулы бала-чага.
Уйнап-көлеп, шау-гөр килә,
Чана тартып таудан шуа.

Әнкәемнең морҗасыннан
Чыгып тора зәңгәр төтен.
Исе таралган тирә-якка
Икмәк пешергән ул бүген.

Гөҗләп тора самовары,
Өстендә чәй чәйнүге.
Өстәлдә җылы икмәге,
Эре шакмаклы шикәре.

Яулыгын артка бәйләгән,
Ул тиргә батып чәй эчә.
Чигәсеннән аккан тирне
Альяпкычына сөртә.

Аш салган казан тутырып,
Бәлеш салган баланнан.
Кичен ашка җыелалар
Каз өмәсендә булганнар.

***

Дөньяда иң кадерле
Минем сөекле әңкәем.
Шулай ук җаныма якын
Минем үз туган телкәем.

Иң беренче туган телем
Бишек җыры белән кергән.
Аннан соң телем татарча
«Әңкәем» дип ачылган.

Әңкәем татарча сөйләргә
Өйрәткән туган телемдә.
Туган телем, татар теле
Яңгырый ул бөтен илдә.

## Гомер көзем

Әллә ничек ямансу бу ел
Әллә үзем картайганга.
Әллә коронавирус чыгып,
Йөрәкне куркытканга.

Көн бик салкын булмаса да
Була бик еш өшегән чаклар.
Картаюның билгеседер бу –
Сирәгәеп бара елмаюлар.

Бар да син теләгәнчә булмый
Була күңел тулган чаклар да.
Ходайдан сабырлык сорыймын
Кычкырып елардай чакларда.

Ярый әле балалар янымда
Күңел тулганда юанырга.
Бар сагышлар онытыла
Алар янәшәдә булганда.



## Гөлләрем

Үзем үстергән чәчәкләргә
Сокланып карап туймыйм.
Иртә таңда моң тараткан
Сандугач тавышын тыңлыйм.

Көн саен иртән иркәләп
Су сибәм гөлләремә.
Йомшак кына җил бөркелә
Назлар өстәп күңелемә.

Һәрберсе төрле төстә
Чәчәк атты матур булып.
Бөркелә һәрберсеннән
Бакчамда хуш ис таратып.

Табигатьнең гүзәллеге
Булса да бары тик язык,
Үзем үстергән чәчәкләр
Бизиләр гомерем көзен.

Матур чәчәкләргә карап,
Яшим көн саен назланып.
Гөлләремнең хуш исеннән
Яшәр өчен дәрт алып.

***

Кайттым әле туган авылыма
Бала чагым узган урынга.
Ниләр язсам да аз булыр
Туган авылым синең турында.

Бала чак – иң бәхетле чак,
Нәрсә кирәген дә белмисең.
Тамагың тук, өстен бөтен
Тик уеннан гына туймыйсың.

Без уйнап үскән урамга
Хәзер асфальт салынган.
Юл читендә яшел үлән
Минем эзне саклаган.

Без үскән кечкенә өй урынына
Бик матур зур йорт салынган.
Әле дә бала чагымны хәтерләтеп
Әнкәемнең сирене сакланган.

Матур, җылы язлар җиткәч
Сирень чәчәкләргә күмелә.
Тирә-якка хуш ис таратып.
Сокландыра күпләрне үзенә.

Нәрсә булган микән тау битенә
Тигезләшеп килә җир белән.
Тау өстендәге салкын чишмә
Астан ага үзе тапкан юл белән.



Гөрләп яккан Урҗа елгасы
Яры биек, суы саеккан.
Су коеныр үскән күлләрем
Күптән инде кипкән, корыган.

Ярларына язлар җиткәч
Оя ясый иде карлыгач.
Бөдрә талларына качып
Моңын суза иде сандугач.

Авылымның аяз кичләрендә
Сандугачлы алсу таңнарны,
Серләшеп һич тә туялмыйча,
Күпме гашыйклар каршылады.

Йолдызлы айлы төннәрдә
Күпме гашыйклар табышкан.
Җырлы-моңлы уенлыкны.
Тик чүп үлән, тигәнәк баскан.

Айлы, гармунлы кичләре
Сандугачлы, моңлы иртәсе.
Синдә калган яшьлек елларым
Чакыра сыман, могаен, тавым.

***

Язлар җиткәч бөдрә талга
Кунып сайрый сандугач.
Мин дә кушылып җырлыймын
Сагышларга түзә алмагач.

Тирәктә качып сайрыйсың
Кайда соң син , сандугач?
Син дә шулай моңаясың
Минем кебек сагынгач.

Ялгыз...
Менә тагын язлар җитте
Бүген синең туган көнең.
Сине котлыйлар чын күңелдән
Балаларың, якын дусларың.

Кәнәгать булып яшисең син
Зарланмыйча юк-барга.
Шушы яшәгән җыйнак йортың
Сиңа үзгә, оҗмах булып тоела.

Абынсаң да язмышыңда
Сикәлтәле тормыш юлыңда.
Егылмадың, тотынып калдың
Ныклы дусларыңнын иңенә.



Балаларыңны ялгыз үстердең,
Оныкларың, хәзер туруннарың.
Мәрхәмәтле, иркен күңелеңә
Хәтта дусларыңны сыйдырасың.

Үкенмә гомер үтте диеп,
Гомер кыскарганга уфтанма.
Яшә киләчәккә өмет белән
Барысы да Аллаһ кулында.

Әни, дәү әни булу зур бәхет
Эләкми ул һәр кемгә дә.
Таяныч, олы терәк булып
Торасың әле син бүген дә.

Эчең тулы сагыш булганда да
Син һәрчак елмаясың, көләсең.
Бу доньяга гомер биргән өчен
Аллаһка мең рәхмәтлесең.

Күпме алда гомер калса да,
Алда нинди язмыш көтсә дә,
Яшә син шатлыкларга күмелеп,
Балалар, оныклар тәрбиясендә.

Тормыш дулкынын каршылап
Бирешмичә алга атлыйсың.
Күпме әниләргә, нәнәйләргә
Үрнәк булып матур яшисең.

# 2020 ел

Кара җирнең өстен каплап
Энҗе йомшак карлар яуган.
Табигатьнең михнәтләре
Әйтерсең, кар астында калган.

Яңа ел – гаилә бәйрәме,
Һәр кеше каршылый өендә.
Шатлык, бәхетләр белән
Каршы алырбыз әле быел да.

Кәбисә ел авыр булды –
Бирде Ходай бик күп сынаулар.
Күп кешенең иңенә төште
Көтелмәгән ачы газаплар.

Олы, ачы кайгыларга салып
Балаларын, туганнарын
Китеп бардылар мәңгелеккә
Танышларым, дус-ишләрем.



Йөрәк сыкрый, күңел әрни
Кичерәбез югалтулар.
Калсын берүк шушы елда
Үзе белән бәла-казалар.

Кабатланмасын җирдә
Быел биргән михнәтләр.
Түгелмәсен күз яшьләре
Яраланмасын йөрәкләр.

Яңа яуган ап-ак карлар
Алып килер әле тазалык.
Бу афәттән арчаланып
Урнашыр җирдә тынычлык.

Яңа ел килсен рәхмәтләре белән
Коронавирус чигенсен.
Урамда йөребез курыкмый
Иркенләп сулап һавасын.

Кәбисә елы төгәлләнү
Бик зур сөенеч булып тоела.
Яңа ел алып килсен шатлык,
Елмаю балкысын йөзләрдә.

# Туган тел

Газиз әти-әни кебек җанга
якын син, туган телем.
Туган телем белән
Кадерлемен, хөрмәтлемен.

Гореф-гадәтләрең белән
Данлы син, туган телем.
Илен саклый, динен саклый
Син минем горурлыгым.

Бөтен җиһанга таралып
Яңгыйрыйсың, туган телем.
Сызылып  аткан таңнар кебек
Балкы син, туган телем.

Кояш нурлары шикелле,
Нурлы син, туган телем.
Сандугачның тавышыдай
Моңлы син, туган телем.

Талгын гына искән җилдәй
Йомшак син, туган телем.
Ап-ак карлар шикелле
Пакъ бит син, туган телем.

Чылтырап аккан чишмәдәй
Саф бит син, туган телем
Курай моңнары шикелле
Дәртле син, туган телем.

Кай җирдә яшәсәң дә
Сөйләш туган телеңдә.
Газиз әңкәңнең теле ул
Онытма син беркайчан да.



***

Хатын-кыз ул бик сылу
Табигый булуы белән.
Ир-атларны гашыйк итә
Үзенең гүзәллеге белән.

Хатын-кызның серлелеге
Табигатьтән бирелә.
Серле карашлары белән
Ир-атны җәлеп итә.

Аның тышкы кыяфәте
Я ягымлы карашы.
Кыланмышы, елмаюы-
Аны яратмыйча буламы?

Хатын-кыз нинди булса да,
Ул бары бер гүзәл зат.
Аллаһ биргән гүзәллеккә
Сокланырга кирәк һәрчак!

***

Йомгак ясар вакыт җиткән
Үткән гомеремне барлап
Белеп булмый кылган гонаһларны
Ходайдан ярлыкавын сорап.

Коронавирустан куркып
Әллә үлем чигенеп тора.
Маңгаема язылган гомерем
Һаман үземдә, үзе юлында.

Мин бәхетле бу доньяда
Мең рәхмәтлемен Ходаема.
Инде 80 яшкә җитсәм дә
Яшәү дәртле әле күңелемдә.

Бу сөенеч түгел мени миңа-
Балаларым һәрчак янымда.
Оныкларым хәлемне белә
Туруным бөтерелә янымда.

Рәхмәтлемен язмышыма
Күрдем маңгаема язганны
Яшим әле чир терелгәнче
Алганчы соңгы сулышны.

Заман белән бергә атлыймын
Һич килми артта каласым.
Яшимен һаман язлар көтеп
Авылымның сулап саф һавасын.



